МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.12.2017 Казан № 1275 од

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И.Иванов йорты” ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында истәлекле урын төре буларак кертү һәм сак предметын, чикләрен һәм мәдәни мирас объекты территорияләреннән файдалану режимын раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законы, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 нчы июнендә кабул ителгән “Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты сыйфатында кертү турында карар кабул итү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 393 нче карары, 2014-нче елның 15-нче декабрендәге дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай нәтиҗәсе нигезендә **боерам:**

1. Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И.Иванов йорты” ачыкланган мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) бердәм дәүләт реестрына “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты сыйфатында кертергә һәм мәдәни мирас объектының төрен – архитектура һәм шәһәр төзелеше һәйкәле итеп расларга.

2. Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының сак предметын расларга (1 нче кушымта).

3. Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрен расларга  (2 нче кушымта).

4. Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга (3 нче кушымта).

5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2017-нче елның 28-нче
декабреннән № 1275 од
боерыгына
1- нче кушымта

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан
“М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль)
әһәмияттәге мәдәни мирас объектының
**сак предметы**

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектының сак предметы буларак түбәндәгеләр билгеләнә:

– бинаның урнашу урынының Лядской бакчасы буйлап тарихи барлыкка килгән корылмаларның композицион-киңлек структурасы формалашуында катнашуы;

– XX гасыр бинасының күләм-ара композициясе: фасад һәм күтәргеч диварлар;

– Тимер киртәле ике маршлы баскыч;

– Төп фасадта тимер киртәле ике балкон:

– Ишек һәм тәрәзә уемнарының (турыпочмакланып төгәлләнүче) урнашу урнашу урыны, формасы һәм үлчәмнәре;

– Тәрәзә уемнарының тутырылыш геометриясе, материалы – агач;

– XX гасыр башы фасад өслекләренең характеры һәм эшкәртү материалы (комплекслы фәнни тикшеренүләр һәм реставрация эшләрен башкару процессында төгәлләнә);

– Очланучы кәрнизләр буйлап биеклек нокталары;


– XX гасыр башы ике кыеклы түбәнең характеры һәм конфигурациясе;

– XX гасыр фасадларының композиция чишелеше: керү төркеме ризалитлары һәм алар өстентәге аттиклы раскреповкалар; кирпеч һәм бизәлешле кәрниз; сандриклы тәрәзәләрнең кирпеч йөзлекләре; тәрәзә төпләре куышларының бизәлешле эшләнеше.

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2017-нче елның 28-нче
декабреннән № 1275 од
боерыгына
2- нче кушымта

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан
“М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль)
әһәмияттәге мәдәни мирас объекты
**территориясенең чикләре**

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картасы (схемасы):**




мәдәни мирас объекты территориясе чиге

мәдәни мирас объекты

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

**төньяк-көнбатыш өлеш:** Мөштәри урамының җөп ягы буйлап, кызыл сызым буенча (7 – 1 борылыш нокталары);

**төньяк-көнбатыш өлеш:** Мөштәри урамыннан бинаның ян капиталь дивары буйлап, бинаның көнчыгыш почмагыннан 5 метр ераклыктагы ноктага кадәр (1 – 4 борылыш нокталары);

**көньяк-көнчыгыш өлеш:** 4-нче ноктадан көньяк-көнчыгышка Щапов урамы юшәлешенә таба, “И.Н.Киселевның керем йорты, 1910 ел, арх. Олешкевич К.С.” мәдәни мирас объекты диварына кадәр (4 – 5 борылыш нокталары);

**көньяк-көнбатыш өлеш:** Мөштәри урамына таба, “И.Н.Киселевның керем йорты, 1910 ел, арх. Олешкевич К.С.” мәдәни мирас объектының ян капиталь дивары буйлап (5 – 7 борылыш нокталары).

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге
мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең
**борылыш нокталары таблицасы**

| Нокта номеры | МСК-16 та нокта координаталары | | 1984 елгы Бөтендөнья геодезик координаталар системасында нокта координаталары (WGS 84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Киңлек, B | Озынлык, L |
| 1 | 476170.500 | 1306480.430 | 55°47'34.21" | 49°08'06.01" |
| 2 | 476168.420 | 1306495.270 | 55°47'34.14" | 49°08'06.86" |
| 3 | 476167.440 | 1306495.180 | 55°47'34.11" | 49°08'06.86" |
| 4 | 476163.970 | 1306517.540 | 55°47'34.00" | 49°08'08.14" |
| 5 | 476125.700 | 1306511.110 | 55°47'32.76" | 49°08'07.77" |
| 6 | 476129.280 | 1306490.520 | 55°47'32.88" | 49°08'06.58" |
| 7 | 476131.990 | 1306475.000 | 55°47'32.96" | 49°08'05.69" |

Татарстан Республикасы
Мәдәният
министрлыгының
2017-нче елның 28-нче
декабреннән № 1275 од
боерыгына
3- нче кушымта

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясен
**файдалану режимы**

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә:**

– мәдәни мирас объектының физик яктан саклануын тәэмин итүгә юнәлтелгән саклау эшләрен башкару, шул исәптән, консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм заманча файдалануга яраклаштыру;

– мәдәни мирас объектының бөтенлеген тәэмин итү таләпләренә каршы килмәгән һәм мәдәни мирас объектының бүгенге шартларда кулланылышын тәэмин итү мөмкинлеген биргән хуҗалык эшчәнлеге алып бару;

– җир биләмәсен файдалану, мәдәни мирас объектын җир биләмәсен һәм капиталь төзелеш объектларын түбәндәге рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча заманча куллануга яраклаштыру (рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары Россия Федерациясе икътисади үсеш министрлыгының 2014 елның 1 нче сентябрендә кабул ителгән 540 нчы номерлы “Җир биләмәләрен фадалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторын раслау турынлагы” боерыгы нигезендә күрсәтелгән):

торак төзелеше (код 2.0),
торак төзелешенә хезмәт күрсәтү (код 2.7),
капиталь төзелеш объектларын иҗтимагый файдалану (код 3.0),
социаль хезмәт күрсәтү (код 3.2),
көнкүреш хезмәте (код 3.3),
сәламәтлек саклау (код 3.4),
белем бирү һәм мәгариф (код 3.5),
мәдәни үсеш (код 3.6),
иҗтимагый идарә (код 3.8),
эшмәкәрлек (код 4.0),
эшлекле идарә (код 4.1),
кибетләр (код 4.4),

банк һәм иминият эшчәнлеге (код 4.5),
ижтимагый туклану (код 4.6),
кунакханә хезмәте (код 4.7),
күңел ачу (код 4.8),
спорт (код 5.1);

– мәдәни мирас объектының югалган элементларын һәм өлешләрен гамәлдәге сызымнар, үлчәмнәр һәм тарихи аналоглар буенча реставрации юлы белән тергезү;

– башкарылучы эшләрнең (шул исәптән динамик йогынты) мәдәни мирас объектына йогынты ясамау шарты белән гамәлдәге инженер инфраструктурасы объектларын капиталь ремонтлау (тышкы суүткәргеч челтәрен, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефон элемтәсе белән тәэмин итү);

– территориядә мәдәни мирас объектын саклауга, файдалануга һәм популярлаштыруга юнәлтелгән төзекләндерү эшләре: мәйданчыкларны, юл чыгу урыннарын түшәүдә традицион материаллар (таш, гранит һәм табигый материалга охшаш башка материаллар) куллану; тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җайланмаларын куллану;

– яшелләндерү: агачларның һәм куаклыкларның кыйммәтле токымнарын утырту; чәчәк түтәлләре һәм газоннар ясау;

– мәдәни мирас объекты фасадында мәгълүмати язулар һәм билгеләмәләрне, мемориаль такталарны мәдәни мирас объектының 1 нче катыннан югарырак күтәрмичә урнаштыру;

– кулланучылар игътибарына оешмаларның җитештерүче (башкаручы, сатучы), җитештерү урыны (адресы) һәм эшләү вакыты турындагы мәгълүматны җиткергән элмә такталарын, 1999 нчы елның 7 нче февралендә кабул ителгән 2300-1 номерлы “Кулланучылар хокукларын яклау” турындагы Федераль законы нигезендә, мәдәни мирас объектының 1 нче катыннан югарырак күтәрмичә урнаштыру. Югарыда күрсәтелгән мәгълүмати конструкцияләрнең биеклеге фриз биеклегенең 2/3 нән һәм теге яки бу конструкцияне урнаштыру чикләрен регламентлаштыру кысаларындагы катлардагы тәрәзә аралары киңлегенең 2/3 нән югары булмаска тиеш. Аркалы тәрәзәләр булган очракта бина катлары тәрәзәләре арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге 2/1гә кадәр кими. Мәгълүмати конструкцияләрнең киңлеге, теге яки бу конструкцияне урнаштыруны регламентлаштыру чикләрендә каралганча, дивар киңлегенең 2/3 өлешеннән дә артык булмаска тиеш;

– мәдәни мирас объекты фасадларын төнге яктырту җайланмаларын файдалану;

– эшләр археология белән берлектә алып барылганда территориянең директив дәрәҗәсен түбәнәйтү, ишек алды территорияләрен вертикаль планлаштыру.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр мәдәни мирас объектларын саклау эшләренә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты тарафыннан бирелгән язмача рөхсәт нигезендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты белән килештерелгән мәдәни мирас

объектларын саклап калу буенча проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәгә, шулай ук проект документациясенә туры китерелеп башкарыла.

Казан шәһәре, Мөштәри ур., 22-нче йорт адресы буенча урнашкан “М.И. Иванов йорты”, XX гасыр башы җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

мәдәни мирас объектын яки аның аерым элементларын, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше тирәлеген саклау белән бәйле булмаган җир казу, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;

капиталь һәм капиталь булмаган төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен төзү;

урам фасадларында һәм түбәнең урам фасадлары ягындагы өлешләрендә кондиционерлар, зур габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын кую;

тышкы реклама чараларын урнаштыру (югарыда күрсәтелгәннәрдән тыш);

фасадларда тышкы мәгълүмат чаралары (элмәләр) урнаштырганда яктыртуның ачык алымын куллану;

җир өстеннән инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы суүткәргеч челтәрен, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) үткәрү;

киосклар, павильоннар, өслекләр, кече архитектура формалары кую, юкка чыкканнарын торгызу искәрмә булып тора;

мәдәни мирас объекты һәм аның янәшәсендәге корылмаларга динамик йөкләнеш тудыручы технологияләр файдалану;

агачларның кыйммәтле токымнарын кисү, санитария максатыннан кисүләр искәрмә булып тора;

мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы көнкүреш калдыклары белән чүпләү.